**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

IV чакырылышның чираттан тыш утырышы

**КАРАРЫ**

10 февраль 2025 ел № 2 Урыссу ш.т.б.

"Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Мактаулы гражданины» исемен бирү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Ветераннар турында»гы 12.01.1995 елның № 5-ФЗ санлы Федераль законы, Россия Федерациясе Президентының «1941-1945 еллар Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек һәм аны үткәрү турында»гы 31.07.2023 елның № 568 санлы Указы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 28.07.2004 елның № 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 15.09.2021 № 65 санлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Мактаулы гражданины турында»гы нигезләмә, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 03.02.2025 елның "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Мактаулы гражданины турында"гы нигезләмәгә өстәмәләр кертү хакында"гы № 1 санлы карары нигезендә, Россия Федерациясе Президенты В.В. Путин, Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов йөкләмәләрен үтәү максатларында һәм 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгын һәм Татарстан Республикасында Ватанны саклаучы елын бәйрәм итүгә әзерлек һәм аны үткәрү кысаларында, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә яшәүче 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында катнашучыларга "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Мактаулы гражданины" исемен бирергә:

- Хәертдинова Мөхтәрәмә Хәертдин кызына, 02.04.1919 елгы;
- Абдуллин Инком Нәҗип улына, 29.09.1926 елгы;
- Миңнекәев Миңнебай Миңнекәй улына, 15.11.1924 елгы.

2. Әлеге карарны Ютазы таңы ("Ютазинская новь") массакүләм мәгълүмат чарасында бастырып чыгарырга, 07.12.2011 ел, ЭЛ № ФС77-47613 санлы, массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклыкны Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек

буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан бирелгән һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы район Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Ютазы муниципаль районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы
Ютазы район Советы Рәисе А.Ә. Шәфигуллин